СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

№ 29-323 28.12.2017 ел

2018 елга Югары Ослан муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел 26-283 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. 2018 елга Югары Ослан муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын кушымта нигезендә расларга

2. ТР Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2018 елга Югары Ослан муниципаль районының хосусыйлаштыруның Фараз планын тормышка ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында (http://verhniy uslon.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Совет рәисе урынбасары,

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В Осянин